ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.12.2024 № 2181

Торак урын мәйданының хисап
нормасы һәм социаль наем шартнамәсе
буенча торак урын мәйданын бирү
нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьялары нигезендә, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1 Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында торак урынның гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына торак урынның гомуми мәйданы 12 кв. метрдан да ким булмаган күләмдә билгеләнә торган торак урыны мәйданының исәп нормасын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында, социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннары белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасын бер гражданга торак урыны гомуми мәйданының 18 кв. метры күләмендә билгеләргә.

3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.

4. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының « Торак урын мәйданының хисап нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданын бирү нормасы турында» 2021 елның 23 апрелендәге 550 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева